ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2008 елның 3 июнендәге 2565 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында нигезләмәнең 2.1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Хәлиуллина шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2017 елның 9 феврале

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.С. Хәлиуллина шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.С. Хәлиуллина «Казан шәһәре муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2008 елның 3 июнендәге 2565 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 2.1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норма шуны билгели: муниципаль торак фондының торак урынын алмаштырырга теләк белдергән торак урын яллаучы кеше вәкаләтле органга тиешле үрнәктә язылган һәм алмаштырылырга тиешле торак урын урнашкан урындагы торак-эксплуатация оешмасы тарафыннан расланган гариза (1 нче кушымта) һәм 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча төзелгән торак-эксплуатация оешмасының белешмәсен тапшыра.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.С. Хәлиуллина 2010 елдан Казан шәһәренең Даурская урамында урнашкан торак урын яллаучысы булып тора, анда ул 1973 елдан бирле яши һәм коммуналь һәм башка хезмәтләр өчен түләп, торакны тоту буенча бөтен чыгымнарны каплап бара. Аның улы 1995 елда өйләнгән, ә хатыны күрсәтелгән адрес буенча 1999 елда теркәлгән булган. 2009 елда аларның никахлары таркалган. 2007 елдан улының хатыны әлеге фатирда тормаган, коммуналь хезмәтләр өчен түләмәгән, ләкин мөрәҗәгать итүченең рөхсәтеннән башка анда үз балаларын һәм оныгын теркәгән. Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, аталган гражданнар әлеге фатирны хосусыйлаштыруга ризалык бирмиләр, гәрчә аларның яшәү урыны булып әлеге торак йорттагы башка фатир тора, ә гражданка Г.С. Хәлиуллина фатирында теркәлүләре формаль гына, шуның белән бу аның торак урын яллаучысы буларак хокукларын боза. Аның раславы буенча, әлеге ситуацияне хәл итүнең бердәнбер реаль ысулы булып фатирны мәҗбүри алмаштыру тора. Ул шулай ук күрсәткәнчә, Казан шәһәренең «Муниципаль торак программалар дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе аның яшәгән торак урынны алмаштыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатенә аларның картотекасында яраклы алмаштыру вариантлары юк дип җавап биргән.

Гражданка Г.С. Хәлиуллина билгеләгәнчә, дәгъвалана торган Нигезләмәгә 1 нче кушымтада расланган гариза формасы буенча мөрәҗәгать итүче үзенең торак мәйданын алмаштырырга сорый торган торак мәйданны

күрсәтергә кирәк. Шул ук вакытта дәгъва белдерелә торган норма гражданның торак урынны алмаштыру варианты булмаганда алмаштыру өчен башка торак урынны сайлау турында гариза бирүгә хокукын күздә тотмый, бу, аның фикеренчә, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.С. Хәлиуллина Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2008 елның 3 июнендәге 2565 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында нигезләмәнең 2.1 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 55 һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарны алмаштыру Россия Федерациясе Торак кодексының 72, 73 һәм 74 статьяларында билгеләнгән кагыйдәләр буенча башкарыла. Торак урынны социаль наем шартнамәсе буенча яллаучы яллауга бирүче һәм үзе белән бергә яшәүче, шул исәптән вакытлыча башка җирдә булган гаилә әгъзаларының язма рөхсәте белән алар биләгән торак урынны социаль наем шартнамәсе буенча башка яллаучыга бирелгән торак урынга алмаштырырга хокуклы (72 статьяның 1 өлеше).

Күрсәтелгән хокукый җайга салуда дәүләт яки муниципаль торак фонд милегендә булган һәм гражданга социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынны алмаштырган вакытта федераль закон чыгаручы андый урын милекчесенең аны алмаштыру вариантларын сайлау бурычын күздә тотмый.

Торак законнары нормаларын гамәлгә ашыру һәм Казан шәһәре муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру процедурасын камилләштерү максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан карала торган тәртип расланган, ул муниципаль торак фондының гражданнар социаль наем шартнамәләре нигезендә биләп торган торак урыннарын алмаштыру кагыйдәләрен билгели.

Гражданнарның торак урынны алмаштыру вариантлары булмаганда җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль милектәге торак урыннарны алмаштыру вариантларын эзләү җирле үзидарә органнары бурычларына керми, чөнки андый вәкаләт гамәлдәге законнарда каралмаган, ул аларның дискрециясе генә булып тора.

Шулай итеп, Муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында нигезләмәнең дәгъвалана торган 2.1 пунктында аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм ул кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган итеп карала алмый. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә гражданка Г.С. Хәлиуллина шикаяте карала алмый. Дәгъвалана торган хокукый җайга салуга мөрәҗәгать итүче фикеренчә максатка ярашлы үзгәрешләр кертү исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Казан шәһәре муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2008 елның 3 июнендәге 2565 номерлы

карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында нигезләмәнең 2.1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Хәлиуллина шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.С. Хәлиуллинага һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 7-О**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**